Чыганак: Арсланова, Ф. Татар Дәүләт җыр һәм бию ансамбле (ансамбльнең 70 еллыгына багышлана) = Государственный ансамбль песни и танца Республики Татарстан / Ф. Арсланова.- Казан: Сүз, 2007. – 239 б.

## Александр Ключарев

Милләте белән рус кешесе булган Александр Сергеевич Ключарев күпкырлы якты таланты белән музыкаль сәнгатебездә аерым бер урын алып тора. Ул — халык музыкасының бөресе булып халык көйләре торганлыгын тирәнтен аңлаган, үзенең эшчәнлеген шушы байлыкны, халык җәүһәрләрен — җырларын, бию-такмакларын, уен кораллары көйләрен җыюдан һәм аларны теркәүдән башлап җибәргән, гомере буе татар сәнгатенә хезмәт иткән композитор. Әмма бу теркәү эше Ключарев өчен беркайчан да үзенә күрә «музыка гербарие»н төзү генә булып калмый: халык көе аның күңелендә, аның иҗатында яши, ул аны яңа сәнгати үрнәкләр белән баета, җырга чын мәгънәсендә җан өрә. Күп кенә халык көйләрен ул үз әсәрләрендә эшкәртеп куллана, кайберләрен, башкаручы буларак, пропагандалый. Үзенең сәнгатькәр дусларын — татар һәм башкорт композиторларын да бу олы эшкә чакыра һәм аларны халык җырлары белән тәэмин итә.

Татар дәүләт филармониясендә Җыр һәм бию ансамбле оешкан көннәрдән алып, А. Ключарев бай репертуар тудыруда иң актив эшләүче шәхес булды. Репертуарын популяр халык җырлары эшкәртмәләре, массакүләм җырлар һәм заманча темага такмаклар, хореографик миниатюралар тәшкил иткән Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле өчен бик күп әсәрләр яза һәм аны танытуда искиткеч зур хезмәт куя. Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбленең барлыкка килүе, аның үсеше һәм яшәеше исеме белән тыгыз бәйләнгән. Татар дәүләт филармониясе каршында хор студиясе оешкач, Зөләйха Әхмәтовага хормейстер вазифасын Александр Сергеевич тәкъдим итә һәм ансамбльнең төп яшәеш стиленә нигез салуга булыша.

1939 елда куелган «Сабантуй» вокаль-хореографик сюитасы (14 номердан тора) лаеклы уңышка ирешеп, ансамбльнең театральләштерелгән программасының асылы булып тора. Соңрак әлеге сюитаның «Җырлыйммы?», «Мәрфуга җыры», «Көрәш», «Яшьләр биюе» номерларыннан алты думбрадан торган ансамбль өчен «Сабантуй» концерт сюитасы туа. Әкренләп композиторның халык материалында иҗат юнәлеше тәмам ачыклана һәм хор өчен эшкәртү төрләре билгеләнә. Еллар үткән саен, композиторның ару-талу белмәс иҗаты хор сәнгате өлкәсендә яңалыкка китерә. Халык җырының бөтен милли колоритын, матурлыгын саклап, аның интонацион һәм ритмик үзенчәлекләрен гармоник яктан баетып, татар халкының күмәк җырларын күп тавышлы, бай фактуралы хор әсәре яңгырашына әверелдерә. Аның тарафыннан 500 дән артык халык җыры һәм инструменталь көй өйрәнелеп, алар ике җыентык булып дөнья күрде (1941 һәм 1955 елларда). А. Ключарев ансамбльдә эшләү дәверендә коллективның һөнәри башкаручылык сыйфатын бик нык үстерүгә ирешә.

Татар җырларын эшкәртүдә А. Ключаревның иҗаты ике юнәлештә үсә. Беренчесе — нинди дә булса кануннардан азат ителгән эшкәртү. Бу төрдәге эшкәртүләр күп очракта хорның а капелла башкаруына нигезләнеп эшләнгән. Әлеге әсәрләр аерым бер образлы драматургияле уйланманы, бик тирән мәгънәгә

ия музыкаль новелланы хәтерләтәләр. Көй барышында күп кенә үзгәртүләргә юлыгып, халык көе әлеге төр композицияләрдә лейттема ролен үти. Тулы музыкаль поэтик образ тудыру максатына хор яңгырашының барлык төсмерләре буйсындырылган. Шундыйлардан «Әңгер-меңгер» (Себер татарлары көйләре темасына) хор миниатюрасын атарга була. Бу эшкәртмә катлаулы формада төзелгән, анда күп кенә татар халык җырларының көйләре бирелә. Салмак, озын, кыска көйләр авторга төрле фактуралылыкны киң кулланырга мөмкинлек тудыра.

Омск өлкәсендә язып алынган борынгы аучылар бәете «Карьят батыр» көе бөеклек һәм тотрыклылык белән аерылып тора. Бу эпик җыр үзенең төзелеше ягыннан рус риваятьләренә һәм хикәятләренә якын — музыка фразаларының һәм ритмик бизәлешләренең кабатлануы, көйнең ирләр тавышына хас яңгыраштa булуы, алмаш ритм җырны тагын да көчәйтә, үстерә. Г. Тукай шигыренә язылган «Пар ат» җырының эшкәртмәсе исә хор өчен сюжетлы күренешне хәтерләтә, һәм бу күренеш хор драматургиясе ысуллары белән оста итеп тасвирланган.

Көй эшкәртмәләренең икенче юнәлеше — киң аудитория тарафыннан күбрәк кабул ителгәне — ялгыз башкаруның асыл традицияләрен алгы планга куя, башкаручыга иркен рәвештә, көйнең бизәкләрен бозмыйча башкарырга мөмкинлек бирә. Хор партиясе күпләгән гади, әмма тулы һәм чиста яңгыраш биргән тавышлар белән баетыла. Мисалга халык арасында аеруча популяр булган «Кара урман», «Фазлуш», «Сарман», шаян җыр «Дим-дим», лирик җыр «Өй артында шомыртым», себер татарлары җыры «Гармун-гармун» — кыскасы, профессиональ һәм үзешчән хор коллективлары репертуарында ныклы урыннарын алган күп кенә җырларны китерергә була. Югарыда әйтелгән җырларның, әлбәттә, беренче башкаручысы – Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле.

«Кара урман» фәлсәфи эчтәлекле борынгы озын көйләр рәтенә керә. Аның текст-сүзләрендә бик күп халыкларның шигырь иҗатына хас булган сәнгати образларның янәшәлеген күрәбез. Бу, үз чиратында, табигатьнең чиксез матурлыгы турында тирән уйлануларны кешенең шушы табигать белән бербөтенлеген рәттән куюдан гыйбарәт. Әсәр текстының авторы күркәм дуслык хисе белән бергә бар тормыш авырлыкларын җиңәргә ярдәм иткән чын, тугры дусларның барлыгын да исбатларга омтыла. Табигатьнең бар гүзәллеген күзәткәндәге уй-кичерешләр, хис-тойгылар музыкада бөтен барлыгы белән чагылыш таба. Халык көе ярдәмендә барлыкка килгән сәнгатьле бизәү чараларының күплеге булган тәэсирне тагын да көчәйтә. Көйнең интонация ягыннан сыгылмалылыгы һәм төрле музыкаль бизәкләргә байлыгы белән беррәттән, автор җырның тирән мәгънәсен дә халыкка оста итеп ачып бирә. «Гармун-гармун» җырына исә эшкәртмә башкачарак уйланылган. Киң колачлы, салмак темплы, күңелле көй характерлы музыкаль картина тудыруга сәбәпче була. Бик күптәннән татар халкының күңелен яулап алган уен коралын тиешле биеклеккә күтәрү теләге белән композитор, фон итеп, хор башкаруында гармунда уйнау имитациясен ала. Әлеге чараны уңышлы башкарып, автор хорны бик уйлап, оста куллана. Көйне өске тавышлар алып бара. Баяннар җырны виртуоз вариацияләр белән баетып матурлыйлар. А. Ключаревның эшкәртмәсе бу җырны үзенчәлекле гимнга әверелдерә. Хор, бик оста һәм кыю рәвештә, сәнгатьчә кулланылган. Әсәрнең рондоны хәтерләткән формасын яңалык дип атарга була.

Авазларны охшату элементларын борынгы «Дүдәк» җырында композитор оста куллана. Хор партитурасыннан татар халкының кыска көйләренә, такмакларына хас тормышчанлык, күңеллелек бөркелеп тора. Әлбәттә, тормышчан күренешләрне тасвирлаганда теләсә кайсы классификация дә шартлы булып кала.

Кайбер әсәрләрне югарыда бирелгән бер төркемгә дә кертеп булмый. Мисалга, сокланырлык шигъри аһәңгә ия лирик «Әллүки» җырын гына искә төшерик. Әлеге җырны беренче төркемгә кертеп булыр иде (хорның бернигә буйсынмыйча иркен үсешен исәпкә алсак), әмма, хор партиясеннән тыш, югарыда төп теманы алып барган башлап җырлаучының нәзек тавышы яңгырый. Бу исә — үз чиратында, икенче төркем эшкәртүләренә хас, һәм «Әллүки»не үзенчәлекле сәнгать эталоны итеп санарга була. «Әрәмәләр арасында» җыры эшкәртмәсе дә әлеге ике төркемнең уртак җимеше булып тора. Башлап җырлаучының партиясе белән аккомпанемент тавышлары бик иркен һәм табигый кушылып биреләләр.

Ладо-гармоник бизәлеше төзелеше ягыннан кыю булган борынгы «Зөбәрҗәт җыры» эшкәртмәсе дә бик матур, ачык мисал булып тора. Ә менә романс жанры стилендә эшкәртелгән «Тәфтиләү» үзенең озын, бизәкле көе белән татар халык җырларының ладо-гармоник үзенчәлекләрен гомумиләштерә.

Башкорт җырларының үзенчәлекле стилендә «Агыйдел», «Таштугай», «Зөлхиҗә» кебек җырларның эшкәртмәләре — композиторның бәһаләп бетергесез иҗат җимеше. Гомумән, Ключарев башкорт җырларын өйрәнү өлкәсендә тирән эз калдырды һәм, профессиональ композитор буларак, иҗатында киң файдаланды.

Хор өлкәсендәге иҗат мирасында А. Ключарев халык җырларын гына эшкәртеп калмый, ул — үзе иҗат иткән әсәрләр авторы да. Иҗатында оригиналь җырлар күп булса да, хор өчен язылганнары чагыштырмача аз дияргә мөмкин.

Халык көнкүрешендә киң таралган җырлы биюләр, биюле җырлар А. Ключарев иҗатының җырны театральләштерүгә илткән аерым бер өлкәсен тәшкил итә.

Композитор тарафыннан уенлы сюжет элементларын эзләү бик кызыклы нәтиҗәләргә китерә. Мисалга биюле җыр «Ак бүрек»не, солист белән хатын-кызлар хорының уен-көлкеле диалогыннан торган борынгы көй «Аппакай-алмакай» эшкәртмәсен, «Пар ат» хор күренешен китерергә була. Шулай ук бу жанрда эшләнелгән театральләштерелгән музыкаль-уенлы «Тула өмәсе» композициясен атарга кирәк. Әлеге композициянең премьерасы 1959 елда Уфада уза. Ул Башкорт дәүләт филармониясе тарафыннан куела, Татарстанда исә «Тула өмәсе»н 1962 елда Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле зур сәхнәгә алып менә. Әлеге музыкаль-уенлы композиция традициясе Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбленең «Бүген бәйрәм» исемле театральләштерелгән программасында үзенең тулаем үсешен ала. Бу программада төрле характердагы номерлар бер-берсе белән бердәм вокаль-хореографик сюита-монтажга тупланган. А. С. Ключаревның ансамбль өчен соңгы күләмле эше — «Аулак өй» музыкаль композициясе. 1969 елда Нәкый Исәнбәт «Аулак өй»не халык театрлары һәм филармония өчен музыкаль уен — 1 пәрдәлек пьеса итеп яза, ул ансамбль өчен бераз кыскартылып, Александр Сергеевичның якын дусты, балетмейстер Фәйзи Гаскәров белән берлектә куела. ТАССРның 50 еллыгына багышланган «Аулак өй» ансамбльнең репертуарыннан төшмичә, әле дә сәхнәдә яшәвен дәвам итә.

Композитор иҗатында лирик җырлар аеруча күренекле урын алып тора. Мәсәлән, «Туган җирем — Татарстан» (Г. Зәйнашева сүзләре). Бу җыр республиканың музыкаль эмблемасына әверелде. А. С. Ключарев —«Татарстан сәламе» (З. Нури сүзләре), «Идел дулкыннары», «Яңа Казан» (М. Хөсәен сүзләре), «Сәрвиназ» (Ә. Ерикәй сүзләре) кебек популяр җырлар авторы.

Композитор иҗат эшен актив җәмәгать эшчәнлеге белән бәйләп алып барды. Озак еллар Татар дәүләт филармониясенең сәнгать җитәкчесе булып эшләде, Татар дәүләт җыр һәм бию ансамблен оештыручыларның берсе һәм төрле еллар-

да аның сәнгать җитәкчесе (1939, 1967—1970) булды, Татарстан Композиторлар берлеге рәисе урынбасары вазифаларын башкарды. 1938 елдан ул Фольклор кабинетының алыштыргысыз җитәкчесе дә булды.

2006 елның февраль аенда А. С. Ключаревның тууына 100 ел тулды. 25 февральдә С. Сәйдәшев исемендәге зур концерт залында узган, композиторның юбилеена багышланган кичәдә Александр Сергеевичның улы Эмиль Александрович Ключарев әтисенең тормышы һәм иҗат юлы турында үзе төшергән «Мой отец Александр Ключарев» фильмын күрсәтте, симфоник оркестр, солистлар башкаруында композиторның әсәрләре башкарылды. Ә 2006 елгы хор ассамблеясы А. С. Ключаревның хор өчен эшкәртмәләр һәм үз әсәрләреннән торган хор концерты белән тәмамланды.

Александр Сергеевичны күреп белгән Казан дәүләт консерваториясе профессоры Афзал Хәйретдинов хатирәләре: «1939—1940 елларда мәдәният дөньясы Мәскәүдә булачак татар сәнгате декадасына әзерләнгән чорда, ул халык уен кораллары оркестры оештырды. Һәркөнне репетиция үткәрә идек. Александр Сергеевич көйне тиз генә отып алып гармонияләштерә һәм теләгән тональлектә уйный иде. О. Лундестремның да, оркестрны Ключаревтан яхшырак белүче юк, дип әйткәне хәтердә.

1953 елда иң яхшы җырга конкурс оештырылды. Жюрида әдәбият әһелләре, башкаручылар утырды. Бөтен җырларны да конкурска авторларын атамый гына күрсәттеләр. Бик җентекләп тикшергәннән соң, 1 — 2 — 3 нче урыннарны һәм бүләкләү грамоталарын билгеләп чыктык. Карасак, беренче өч урын да А. С. Ключаревныкы булып чыкты...».

Танылган галим, профессор Мәхмүт Нигъмәтҗанов хатирәләрен дә искә төшерик: «Минем буынга аның белән якыннан аралашырга һәм хезмәттәшлек итәргә, татар халык темаларына кабатланмас импровизацияләрен тыңларга насыйп булды. Язучылар арасында аның бик якын дуслары булды, ә музыкантлар өчен ул — татар халык музыкасы буенча киңәшче-консультант иде. Күп еллар дәвамында үзешчән авторларның иҗат семинарлары белән җитәкчелек итте. Александр Сергеевичның музыка өлкәсен генә түгел, әдәбиятны, этнографияне да тирәнтен белүе күпләрне сокландыра иде».

1933 елда «Коммунист» газетасында А. С. Ключаревның яшьтәше, якын дусларының берсе Муса Җәлил аның концертыннан соң: «Мы можем от этого молодого таланта ждать большого вклада в татарскую советскую музыку», — дип язды. А. С. Ключарев — композитор, музыкант буларак 1930 елдан 1972 елга кадәр татар музыкасының бөтен борылышларында, тормышында, кадрларын әзерләүдә, гомумән музыкаль тормышта иң актив эшләгән кеше. Муса Җәлилнең композитор таланты турында алга карап фикер йөртүе тулысынча акланды. Ул — композитор-музыкант, татар музыка тарихында тирән эз калдырган шәхес. Татар музыкасының кайсы гына тармагына килмә, Шәрекъ дөньясында бу дәрәҗәдә тирән, музыка «эченә» кереп атаклы музыкант буларак эшләгән шәхесләр юк. Ул фольклор буенча татарлар өчен энциклопедия иде. Берәр сорау туса аңа мөрәҗәгать итәләр, нәрсәгә булса критерийлар аннан килә иде.

Солист-музыкант буларак, ул татар музыкасының нечкәлекләренә — ритмикасына, моңына, хореографиясенә керде. Шуңа да Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле өчен Ключаревтан да уңышлырак музыка язган кеше булмады диярлек. Бу аның оркестр өчен язган музыкасында да сизелә.

Ключаревның татар музыкасына ясаган йогынтысы, керткән өлеше гаять зур. Аның һәр жанрын да, һәр әсәрен дә башкаручы теләп ала. Безнең бурычыбыз —

А. С. Ключаревның иҗатын өйрәнү, аның әсәрләрен башкару, аның иҗатын мәңгеләштерү.

РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстанның халык артисты, Г. Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе композитор А. С. Ключаревның язмышы һәм иҗаты бик үзенчәлекле. Милләте белән рус булып, рус мохитендә үсүенә карамастан, ул — татар һәм башкорт профессиональ музыкасына нигез салучыларының берсе буларак танылган шәхес. А. Ключарев үзенең эшчәнлеге белән музыкаль образлар тудыру өчен халык көйләренең иң яхшы сәнгати нигез икәнлеген раслый. Җыр аның өчен гомере ахырынача мәңге саекмаган иҗат чишмәсе булып кала.

Халык җәүһәрләрен тыңлаучыга беренчеләрдән булып ирештерүче буларак, композитор алар ярдәмендә хәзерге заман кешесенең эчке дөньясына, тормышына тирән мәгънә, кешелеклелек өстәргә омтыла. Ул халыкның рухи байлыгын, тормышны яратуын, оптимистик кәефен һәр әсәрендә ачып бирә.

А. С. Ключарев — куйган максатына, үз табигатенә тугры калып, халкыбызның әхлакый һәм иҗади традицияләрен дәвам иттереп, татар музыкасы тарихында бай мирас калдырган бөек музыкант-композитор.

## Фәйзи Гаскәров

Фәйзи Гаскәровның шәхси тормышы катлаулы һәм серле дә. Ул үзе: «Мин әти-әниемне хәтерләмим, милләтем буенча кем икәнлегемне дә белмим — башкортмы мин, татармы, әллә тунгусмы», — дия иде, дип яза Ф. Гобәйдуллина.

Фәйзи Әдһәм улы Гаскәров 1912 елның 21 октябрендә Уфада (кайбер мәгълүматлар буенча, Бөре шәһәрендә) туа. Балалар йортында тәрбияләнә, ата-анасын хәтерләми, ятим үсә, Башкортстанның Бөре шәһәрендәге балалар йортында үзенең дүрт елын (1919—1923) үткәрә. Идел буенда һәм Уралда яшәүчеләр, ачлык елларында вакытлыча булса да, балаларны яшәү мөмкинлекләре чагыштырмача уңайрак төбәкләргә чыгарырга тырышалар. Шулай итеп, Фәйзи дә Белоруссиягә эләгә. Ул төрле милләт вәкилләре арасында үсә

Фәйзи кечкенәдән үк музыкаль сәләткә ия бала була. Балалар йортында тәрбияче Гөлсем апа аны тальян гармунда уйнарга өйрәтә. Уфада театр техникумы ачылгач, балалар йортының сәләтле балаларын төрле һөнәрләргә укытырга алалар. Фәйзи Гаскәровка фортепиано буенча укырга тәкъдим итәләр. Техникумда Фәйзи Башкорт күчмә театры директоры белән очраша. Актерлар коллективында кечерәк кенә бию төркеме дә була. Музыкант һәм биюче буларак, бу театр белән ул күп кенә башкорт авылларын, Чиләбе, Самара, Саратов, Ульян өлкәләрен, күрше республикаларны йөреп чыга. Театрда барлык уен коралларында уйнарга өйрәнә, иң яратканы бәрмә уен кораллары булса да, гармунда да бик теләп уйный, башкорт, татар, рус, украин биюләрен бии, ләкин иң яратып кабул ителә торганы лезгинка була.

Авылларда спектакльдән соң еш кына традиция буенча яшьләр уены башлана һәм гадәттә таң атканчы дәвам итә. Монда җырлар, биюләр, әйлән-бәйлән әйләнү, төрле уеннар популяр була. Күзәтүчән Гаскәров барысын да истә калдыра, халык уеннарында үзе дә катнаша.

Уфага гастрольләр белән опера-балет театры коллективы килгәч, ул классик бию дәресләренә йөри. Театрның профессионал балетмейстеры Гаскәровның тырышлыгын, табигый һәм профессиональ мөмкинлекләрен күреп, аңа балет мәктәбендә укырга тәкъдим ясый.